КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 июль г.Казань № 735

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районында «М-7 «Волга» – «Керәшен Казысы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районында «М-7 «Волга» – «Керәшен Казысы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен «Гринстори» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган кишәрлек милекчесе) милкендәге Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балыклы Чүкәй авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 18 662 кв.метр мәйданлы, 16:34:021002:90 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 147 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы Чүкәй авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «М-7 «Волга» – «Керәшен Казысы» автомобиль юлын төзү» объектын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы чикләрендә урнашкан территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2018 ел, 18 апрель, 9 нчы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балыклы Чүкәй авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 18 662 кв.метр мәйданлы, 16:34:021002:90 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин